ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**V чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**V созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.


**КАРАР**
22.09.2025 ел

**РЕШЕНИЕ**
№01-07

## Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләрен туктату турында

"Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, "Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставының 50 статьясы нигезендә, Актаныш район судының 2025 елның 16 маендагы карарын үтәү йөзеннән, Актаныш муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Ильясов Рөстәм Алмаз улын коррупциягә каршы тору турындагы законнар таләпләрен бозган өчен: «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273 номерлы Федераль законның 13.1 статьясындагы 1 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында каралганча, яклар конфликтын булдырмау һәм җайга салу чараларын күрмәве, шулай ук үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган һәм тулы булмаган белешмәләр биргән өчен ышанычын югалтуга бәйле рәвештә вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатырга.
2. Ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән затлар реестрына кертү өчен Р.А.Ильясов турында белешмәләрне вәкаләтле органга җибәрергә.
3. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең отставкасы турында» Актаныш муниципаль районы Советының 2025 елның 22 гыйнварындагы 41-01 номерлы карарын юкка чыгарырга.
4. Карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Актаныш муниципаль районы
Советы рәисе

Л.Р.Зарипов